ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Физик культура һәм спорт турында” Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 пунктында “спорт разрядлары” сүзләреннән соң “, тренерларның квалификация категорияләре, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләрнең квалификация категорияләре” сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

“$4^1$) Татарстан Республикасы территориясендә студентлар арасында (шул исәптән студентларның спорт лигалары арасында) үткәрелә торган регионара, гомумроссия һәм халыкара спорт ярышларын оештыруда һәм үткәрүдә катнашырга;”;

2) 14 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14 статья. **Спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары. Спорт судьяларының, тренерларның һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләрнең квалификация категорияләре**”;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасында спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары, шулай ук спорт судьяларының, тренерларның һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге

белгечләрнең квалификация категорияләре Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.";

в) 3 өлештә "шушы категорияләрне бирү өчен кандидатларга карата" сүзләрен "тиешле категорияләрне бирү өчен" сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

"6. Тренерларга һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре Федераль законның 22 статьясы нигезендә бирелә. "Иң югары квалификация категориясендәге тренер", "беренче квалификация категориясендәге тренер", "физик культура һәм спорт өлкәсендә иң югары квалификация категориясендәге белгеч", "физик культура һәм спорт өлкәсендә беренче квалификация категориясендәге белгеч" квалификация категорияләре тиешенчә физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органы тарафыннан федераль башкарма хакимият органнары гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкармый торган оешмаларда үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы тренерларга һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә бирелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 июнь
№ 44-ТРЗ